РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 5 июне | Кукмара ш. | № 289

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы карары проектын (1 нче кушымта) хупларга.

2. Кукмара район Советының 2018 елның 27 июлендәге 168 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кукмара муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

3. Кукмара муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашуы тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Билгеләргә:

4.1. Ачык тыңлауларны үткәрү датасы – 2020 елның 6 июле.

4.2. Ачык тыңлауларны үткәрү вакыты – 10: 00 сәгать.

4.3. Үткәрү урыны – Кукмара муниципаль районы Советының утырышлар залы, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Ленин ур., 13.

5. 2020 елның 8 июненнән дә соңга калмыйча, әлеге карарны һәм аңа кушымталарны «Интернет» челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев

Кукмара муниципаль районы Советының 2020 елның 5 июнендәге 289 номерлы карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кукмара муниципаль районы Советы карары проекты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Уставының 51 статьясына прокурорның 2009 елның 19 июнендәге 02-08-02/2019 номерлы протестын карап, Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 30 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Район Советы депутаты хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, профсоюз органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференциядә) катнашырга;

б) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына алдан хәбәр итеп, коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, профсоюз органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашырга;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында район мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итәргә;

г) идарә органнарында һәм район аны гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булган оешманың ревизия комиссиясендә район мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итәргә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, бүтән түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) идарә органнары, попечительлек яки күзәтчелек советлары, чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган башка оешмалар һәм Россия Федерациясе территориясендә эшли торган аларның структур бүлекчәләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса.»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 7 өлешенең 2 пунктындагы «б» пунктчасында һәм «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 3.5 өлешенең 2 пунктында каралган очракларда муниципаль вазыйфа биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы зат, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча Татарстан Республикасы Президентына алдан хәбәр итеп, коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез катнашырга хокуклы.

2. 82 статьядагы 4 пунктның гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Әлеге карар, әгәр законнарда үз көченә керүнең башка сроклары каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, халыкка рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев

К укмара муниципаль район Советының 2020 елның 5 июнендәге 289 номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кукмара муниципаль районы Советы карары проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның анық буенча фикер алышуда катнашуы тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы карар проектына тәкъдимнәр Кукмара муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Кукмара ш., Ленин ур., 13 йорт, яки 2-70-54 факсы буенча язма рәвештә.

Тәкъдимнәр, караны «Интернет» челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырганнан көннән алып, бер ай дәвамында эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар Кукмара ш., Ленин ур., 13 йорт адресы буенча, шәхсән яки почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «ачык тыңлаулар» дигән тамга белән), шулай ук 2-70-54 факс буенча бирелә.

Гаризалар ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Кукмара муниципаль районы башлыгы С. Д. Димитриев